# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЯШЕЛ УЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ТҮБӘН УРЫСБАГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**30 сентябрь 2020 ел** **№8**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәт өчен түләү, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында" карары нигезендә, Түбән Урысбага авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 2020 елның 1 октябреннән билгеләргә:

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының " Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгына ай саен 15 759 (унбиш мең жиде йөз илле тугыз) сум күләмендә акчалата вознаграждение түләү һәм 8 826 сигез мең сигез йөз егерме алты) сум күләмөндә ай саен акчалата поощрение түләү,

2. 2020 елның 1 октябреннән ел саен түләнә торган отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү күләмен билгеләргә:

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының "Түбән Урысбага авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгына 15 759 (унбиш мең жиде йөз илле тугыз) сум сум күләмендә;

3. 2020 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен кушымта нигезендә билгеләргә.

4. Әлеге карарның 1-3 пунктларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итү тиешле елга Түбән Урысбага авыл җирлеге бюджетында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Түбән Урысбага авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 апрелендәге 138 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга «Татарстан Республикасы

Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәт өчен түләү, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында» (Түбән Урысбага авыл җирлеге Советының 2018 елның 12 ноябрендә кабул ителгән 163 номерлы «Түбән Урысбага авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 апрелендә кабул ителгән 138 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләмнәрен, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында " гы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән).

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Яшел Үзән муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм шулай ук Түбән Урысбага авылы, Центральная урамы, 62а йорт (җирлек хакимияте бинасы), Түбән Урысбага авылы, Үзәк урамы, 63а йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан Түбән Урысбага авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

**Түбән Урысбага**
**авыл җирлеге башлыгы** **Х.Х.Сибгатуллин**

Түбән Урысбага авыл җирлеге
Советы 30 сентябрь 2020ел № 8
карарына кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ " ТҮБӘН УРЫСБАГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ РАЗМЕРЛАРЫ

| **Муниципаль хезмәт вазыйфаларының исемнәре** | **Айлык вазыйфаи оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|
| Түбән Урысбага авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) | 15 293 |
| Әйдәп баручы белгеч | 12 763 |